| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Бөек географик ачышлар | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |
| Рельеф | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |
| Елгалар. Эчке сулар | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |
| Үсемлекләр | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |
| Хайваннар | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |
| Климат | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 |

# «Үз уеның»

## Африка **материгы** буйлап сәяхәт

Мамадыш  муниципаль районы Шәмәк төп гомуми белем мәктәбе география һәм биология укытучысы  Шарипова Ә.Ә



# Бөек географик ачышлар

## 10 балл

- Материкның төньяк-көнчыгыш өлешенә, культуралы үсемлекләрне өйрәнү өчен, экспедиция оештырыла. Аны кем җитәкли?

**Җавап**

- Николай Иванович Вавилов



# Бөек географик ачышлар

**20 балл**

- Португалия сәяхәтчесе, Һиндстанга диңгез юлы ачуны тәмамлап, Көньяк Африканы борылып үтә, материкның көнчыгыш ярлары буйлап бара, европалардан беренче булып Һинд океаны аша чыга. Бу кем?

**Җавап**

- Васко да Гама



# Бөек географик ачышлар

**30 балл**

- Күренекле инглиз тикшеренүчесе, ул Көньяк Африканы көнбатыштан көнчыгышка таба кисеп үтә, Замбези елгасын тикшерә, анда матур шарлавык ача.

**Җавап**

- Давид Ливингстон



# Бөек географик ачышлар

**40 балл**

- Африканы тикшерүгә рус галимнәре дә өлеш кертә. Шуларның иң күренеклесе Үзәк һәм Көнчыгыш Африка буйлап сәяхәт итә, материкның бу районнарындагы табигать һәм анда яшәүче халыкның тормышы турында кызыклы мәгълүматлар җыя. Бу галимнең исеме?

- **Җавап**
- Василий Васильевич Юнкер



# Бөек географик ачышлар

**50 балл**

- 1487 нче елдан 1488 нче елга кадәр аның судносы Африканың көньяк ярына барып җитә, ләкин аңа кире Португалиягә кайтырга туры килә. Бу кем була? Аның тарафыннан ачылган борын ничек атала?

**Җавап**

- Бартоломео Диаш, м. Доброй Надежды
- 




# Рельеф

**10 балл**

- Материкта иң биек вулкан?

**Җавап**

- Килиманджаро 5895 м.



# Рельеф

**20 балл**

- Материк урнашкан плита hәм платформа ничек атала.

**Җавап**

- Африка плитасы
- Африка платформасы

# Рельеф

**30 балл**

- Иң биек тау түбәсе.

**Җавап**

- Кения, 5199 м



# Рельеф

**40 балл**

- Африка материгында нинди яшьтәге таулар урнашкан?

**Җавап**

- Борынгы таулар: Кап һәм Дракон таулары; яшь тау: Атлас





# Рельеф

**50 балл**

- Плиталар нинди юнәлештә хәрәкәт итә?

**Җавап**

- Төньяк-көнчыгышка хәрәкәт итә

# Елгалар. Эчке сулар.

**10 балл**

- Африканың иң озын елгасы.

**Җавап**

- Нил



# Елгалар. Эчке сулар.

**20 балл**

- Африканың иң мул сулы елгасы.

**Җавап**

- Конго



# Елгалар. Эчке сулар.

**30 балл**

- Африкадагы атаклы Виктория шарлавыгы урнашкан елга.

**Җавап**

- Замбези



# Елгалар. Эчке сулар.

**40 балл**

- Африкадагы бу күлне Байкалның сеңлесе дип атыйлар. Аның озынлыгы Байкал күленнән дә артыграк, киңлеге дә Байкалныкы чамасында.Тирәнлеге буенча гына Байкал күленнән бераз калыша. Бу нинди күл?

**Җавап**

- Танганьика



# Елгалар. Эчке сулар.

**50 балл**

- Африканың  Сахара чүлендә үзенә коючы елгалар һәм яңгырларга бәйле рәвештә үз мәйданын үзгәртүче күл бар. Аның әйданы 11000 кв. км дан алып 18000 кв. км га чаклы үзгәрә. Бу кайсы күл?

**Җавап**

- Чад.


# Үсемлекләре

**10 балл**

- Үрмәләүче Африка үсемлеге.

**Җавап**

- Лиана



# Үсемлекләре

**20 балл**

- Бу агач уттан курыкмый, озынлыгы 25 м га җитә, кәүсәсенең
- юанлыгы 45 м, җимеше кыярга охшаган. Бу нинди агач?

- **Җавап** Баобаб



# Үсемлекләре

**30 балл**

- Үзагачы кара яисә куе яшел төстә. Бу агачны кыйммәтле мебель ясауда кулланалар.

**Җавап**

- Эбен агачы



# Үсемлекләре

**40 балл**

- Бу үсемлек Намиб чүлендә үсә. Аның кәүсәсе җир өстеннән 50 см га гына күтәрелә. Кәүсәнең очыннан 3 метрга кадәр җитә торган каты кабыклы ике тыгыз яфрак үсеп чыга. Бу үсемлек 150 елдан артык яши ала. Бу үсемлек ничек атала?

**Җавап**

- Вельвичия



# Үсемлекләре

**50 балл**

- Бу агач – Африка оазисларында яшәүче халыкларның төп яшәү чыганагы. Ул аларга күләгә, азык, төзелеш материалы – кыскасы, яшәү өчен барысыын да бирә дияргә мөмкин. Бу агачның җимешләре сусыл һәм татлы. Җансыз чүлле өлкәләрдә ул кешегә яшәү көче бирә. Сез бу агачны беләсезме?

**Җавап**

- Хөрмә пальмасы



# Хайваннары

**10 балл**

- Африкадагы экваториаль урманнарның эре ерткыч хайваны.

**Җавап**

- Каплан (леопард)



# Хайваннары

**20 балл**

Бу чебен  зарарлы һәм әрсез. Ул хайваннар өчен дә, кешеләр өчен дә чын бәла. Ул тешләүдән туган йокы авыруыннан кешеләр һәм хайваннар үлә.Бу зарарлы чебенне беләсезме?

**Җавап**

- Цеце чебене



# Хайваннары

**30 балл**

- Жирафлар нәселеннән, Африка материгында гына яши.

**Җавап**

- Окапи



# Хайваннары

**40 балл**

- Африка саванналарында тереклек итүче бу эре хайванны иң һөҗүмчән дип йөртәләр. Гадәттә ул беренче булып һөҗүм итә.

Саванналарда барлык җәнлекләр дә аңа юл бирә. Нинди коточкыч хайван икән бу?

**Җавап**

- Мөгезборын



# Хайваннары

**50 балл**

- Үзәк Африкада яшәүче бу хайванны да аеруча куркыныч хайваннар рәтенә кертәләр. Мускуллары ачык беленеп торган хайванның авырлыгы бер тоннага җитә. Ул кәкре мөгезле, бик әйбәт күрә, ишетә һәм исне тоя. Монысы нинди хайван?

**Җавап**

- Африка буйволлары



# Климат

**10 балл**

- Бу климат поясы 2 к.к. һәм 5 т.к. тә урнашкан

**Җавап**

- экваториаль пояс

# Климат

**20 балл**

- Ел буена эссе һәм коры

**Җавап**

- тропик

# Климат

**30 балл**

- Ел буена җылы һәм дымлы

**Җавап**

- экваториаль пояс

# Климат

**40 балл**

- Җәй көне эссе, болытсыз, күләгәдә + 50 С.

**Җавап**

- тропик

# Климат

**50 балл**

- “Һава түзә алмаслык бөркү, кешегә дә, хайванга да тын алу кыен. Һава җитми, әйтерсең лә ул, өскә күтәрелеп, инде офыкны бөтенләй каплап алган кызгылт-көрән караңгылык белән очып киткән. Ә ярты сәгатьтән  соң “утлы җил” чыга...” Төньяк Африка чүлләрендәге комлы давылны ничек атыйлар?

**Җавап**

- Комлы давыл – сәмум. Сәмум агулы, агуланган дигәнне аңлата